# КАРАР

**25 ноябрь, 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылында поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- чишмәләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү (ремонтлау) (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Ошторма Юмья авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар һәм колонкалар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Ошторма Юмья авылы зираты коймасын урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Ошторма Юмья авылында балалар уен, спорт мәйданчыгы территориясен һәм һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган һәйкәлне карап тоту һәм төзекләндерү;

Ошторма Юмья авылының вак таш җәелгән урам юлларын төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Ошторма Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2021 елның 25 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 322 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 235 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 148 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 148 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), призыв буенча хәрби хезмәт үтүче гражданнар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Оштырма Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ошторма Юмья авылының вак таш җәелгән урам юлларын төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- чишмәләрне, су башняларын һәм су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү (ремонтлау) (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Ошторма Юмья авылы зиратын коймалау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- балалар уен мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Ошторма Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ошторма-Юмья
авыл җирлеге башлыгы С.В. Тимофеев